**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясепоселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**13 декабрь, 2023 ел** **№ 361**

**Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасының хокукый хәлен камилләштерү турында» 2015 елның 02 февралендәге 424 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Биектау муниципаль районы Советының 2015 елның 02 февралендәге 424 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесе турында» Нигезләмәгә (10.08.2022 №187 карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 бүлекнең 3.3.1. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.1. Палата эчке муниципаль финанс контроле вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда:

- тикшерүләр, ревизияләр һәм тикшеренүләр үткәрә;

- контроль объектларына актлар, бәяләмәләр, тәкъдимнәр һәм (яисә) күрсәтмәләр җибәрә;

- бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган хокукый актлар нигезләмәләренең, шул исәптән дәүләт (муниципаль) учреждениеләренең бухгалтерлык исәбенә һәм бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын төзүгә һәм тапшыруга таләпләр билгели торган нигезләмәләренең үтәлешен контрольдә тота;

- Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан гавами норматив йөкләмәләрне һәм физик затларга башка түләүләр буенча йөкләмәләрне билгели торган хокукый актлар нигезләмәләренең үтәлешенә контрольне, дәүләт (муниципаль) мөлкәте белән идарә иткәндә һәм эш иткәндә һәм (яисә) аннан файдаланганда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларының керемнәрен формалаштыру һәм чыгымнарын гамәлгә ашыруны, шулай ук тиешле бюджеттан, дәүләт (муниципаль) контрактлардан акчалар бирү турында шартнамәләр (килешүләр) шартларының үтәлешенә контрольне гамәлгә ашыра;

- бюджеттан акчалар бирү турында шартнамәләрне (килешүләрне) үтәү максатларында төзелгән шартнамәләр (килешүләр) шартларын үтәүгә, шулай ук әлеге Кодекста каралган очракларда, шартнамәләрне (килешүләрне) үтәү максатларында төзелгән дәүләт (муниципаль) контрактлары шартларын үтәүгә контрольне гамәлгә ашыра;

- бюджет акчаларын (бюджеттан бирелгән акчаларны) бирү һәм (яисә) файдалану нәтиҗәләре турындагы хисапларның, шул исәптән дәүләт (муниципаль) программаларын гамәлгә ашыру турындагы хисапларның, дәүләт (муниципаль) бурычларын үтәү турындагы хисапларның, бюджеттан акчалар бирү нәтиҗәләлеге күрсәткечләре кыйммәтләренә ирешү турындагы хисапларның дөреслеген контрольдә тота;

- дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турындагы Россия Федерациясе законнарында каралган сатып алулар өлкәсендә контрольне гамәлгә ашыра;

- Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе бюджет законнарының башка актлары нигезендә Россия Федерациясе Бюджет кодексында каралган мәҗбүр итүнең бюджет чараларын куллану турында карарлар кабул итәргә вәкаләтле органнарга һәм вазыйфаи затларга мәҗбүр итүнең бюджет чараларын куллану турында хәбәрнамә җибәрә;

- административ хокук бозулар турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә административ хокук бозулар турындагы эшләр буенча производствоны гамәлгә ашыра. Тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру формалары булып тикшерү, ревизия, тикшеренү, операцияләрне санкцияләү тора.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы порталының рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http//vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Башлыгы урынбасары Ә.Ш. Шакировка йөкләргә.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф. Хисаметдинов